Тема :
«Белем бирүдә федераль дәүләт стандартын гамәлгә кую чорында татар телен укытуда инновация»

Проектның *максаты*: белем бирүдә инновацион якын килүне үстерү.

*Бурычлар*:

- укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уяту;
- аның танып-белү активлыгын үстерү;
- укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- белемнәрен тирәнәйтү.

**Проектның *объекты*:** татар теле дәресләрендә инновацион укыту- методик комплектлары һәм педагогик технологияләр.

**Кулланылган тикшеренү методлары:** эзләнү-тикшеренү, мәгълүмат-фактларны чагыштыру һәм гомумиләштерү.

Чыгарылыш эшенең ***структурасы*** керештән, ике бүлектән, йомгаклау өлешеннән, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Хезмәтнең ***гамәли кыйммәте*** шуннан гыйбарәт: эзләнү-тикшеренүләр барышында тупланган материал, тикшерү нәтиҗәләре махсус һәм югары уку йортларында әдәбият һәм тел буенча үткәрелә торган махсус курсларда, семинарларда кулланылырга мөмкин.

Яңалык – ул укыту процессына караган яңа чара (яңа метод, яңа методика, яңа технология)

# Педагогик инновация

* белем бирүгә яңалыклар кертүче максатка юнәлтелгән үзгәрешләр;
* яңалыкларны үзләштерү процессы;
* яңа методикалар һәм программалар эшләү, аларны укыту процессында куллану.

# Педагогик технологиянең 3 аспекты:

1. Фәннилек

2. Белем бирүне планлаштырып, эш нәтиҗәсенә ирешүнең максаты, эчтәлеге, методлары

3. Шәхес үзенчәлеген искә алып, төрле чаралар кулланып оештыру.

# Иҗади үсеш технологиясе

“Иҗадилык – үз шәхесеңне, фикерләвеңне, аң һәм интеллектыңны даими камилләштерү. Иҗади эшчәнлектә кеше үсә, махсус тәҗрибә туплый, үзенең табигый сәләтен һәм мөмкинлеген ача, ихтыяҗын канәгатьләндерә. Шул рәвешчә, иҗадилык кеше тормышын алга илтүче төп көчкә әверелә” (Ә.З.Рәхимов)

# Тәнкыйди фикерләү технологиясе

* кызыксыну;
* эзләнү;
* үз-үзеңә сорау кую (ни өчен?);
* җавап табу;
* үз фикереңне булдыру;
* башкалар фикеренә колак салу;
* кабул ителгән карарга тәнкыйть күзлегеннән карау.

# Бу технология укучыга нәрсә бирә:

* мәгълүматның кабул итү тәэсирен көчәйтә;
* кызыксыну уята;
* критик фикерләргә этәрә;
* җаваплылык, үзаң формалаштыра;
* белем алуның сыйфатын күтәрә;
* бергәләп эшләтә;
* үзеңне замана белән бергә атлаучы шәхес итеп тоярга мөмкинлек бирә.

## Укытучыга нинди мөмкинлекләр ача:

* сыйныфта ачык һәм эшлекле мөнәсәбәт булдыра;
* сыналган уку-укыту модельләрен; нәтиҗәле методларны файдаланырга этәрә;
* үз эшчәнлеген анализлый белүне таләп итә;
* һөнәри осталыкны ачарга ярдәм итә

# Төп критерийлары:

* Укучы белән укытучы арасында киртә, “барьер” юк. Алар әңгәмәдә, укыту эшчәнлегендә икесе дә тигез хокуклы.
* Укытучы мәгълүмат чыганагы түгел, ә юнәлеш, юл күрсәтүче буларак карала. Ул укыту эшчәнлеген кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештыра.

# *Нәтиҗәләр:

* укучыларга белем һәм күнекмәләр алганда инновацион якын килү- иң әһәмиятле этапларның берсе булып санала;
* укучы яңа теманы үзе эзләүче, тикшеренүче сыйфатында үзләштерергә тиеш;
* дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!!!